“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе”
дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе

Педагогик
киңәшмә утырышында каралды
“29”август 2022 ел. №1
Интернат мәктәбе директоры
_______________Л.Р.Мартынова
Боерык белән кертелде №98-0
“ 31 ” 08 2022 ел

**7нче КОРРЕКЦИЯ** сыйныфы өчен
**туган (татар) теленнән һәм әдәбияттан уку предметы буенча**
**эш программасы**
Атнага **0,5** сәгать**,** елга **17_** сәгать

Төзүчесе:
**татар теле һәм әдәбият укытучысы Мөхәммәтҗанова Л.Ф.**

Килешенгән:
Директор урынбасары________И.Б.Шарифуллина

МБ утырышында каралды, беркетмә№1 “26 ”август 2022 ел
МБ җитәкчесе ___________М.Г.Шәрипова

Әлмәт 2022 ел

**Туган (татар) теленнән эш программасы 7-сыйныф**
**Аңлатма язуы**

**Эш программасы статусы.**

1. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (21.12.2012, №273-ФЗ)
2. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы Законы (25.10.1991, №1807-1, ред.12.03.2014)
3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен ФГОС нигезендә башлангыч гомуми белем бирү буенча җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы.
4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Инвалид балаларны өйдә тәрбияләү һәм укыту тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында" 16.06. 2008 ел, 401 нче карары.
5. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (22.07.2013, № 68-ЗРТ)
6. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (8.07.1992, №1560-XII; ред. 12.06.2014№53-ЗРТ)
7. Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы(1 — 11 нче сыйныфлар) /Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан:2018
8. Әлмәт интернат мәктәбендә дисциплина, предмет, уку курсларының эш программалары раслануы, эшләү тәртибе, структура нигезләмәсе 31.08.22 № 98-О.
9. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына программасы.
10. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына базислы уку-укыту планы.
11. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы турында нигезләмә (локальный акт).

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары:**

- татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү, татар балалар әдәбиятының күренекле язучылары, аларның иҗаты белән таныштыру;
- татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
- программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
- карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
- татар теле дәресләрендә алган белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту, сөйләмдә куллану, тәкъдим ителгән текстларны яттан өйрәнү;
- татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
- татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
- халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

Рус балаларына татар теленә өйрәтүнең төп максаты- гамәли максат, ягъни, телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә- көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү. Гомуми белем бирү

максаты укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт.
Тәрбияви максат балаларның рухи дөньясын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре
арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

Гамәли максатка ирешү өчен, укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру; диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү, дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру, татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү бурычлары куела.

Тәрбияви максатка ирешү өчен, укучыларның акыл хезмәте күнекмәләрен булдыру; татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү;
татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру мөһим.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 нче маддәсе һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы” Закон нигезендә татар һәм рус телләре – тигез хокуклы дәүләт телләре булып тора. Татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү телне аралашу чарасы, шулай ук укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру ысулы буларак үзләштерүдән гыйбарәт. Татар телен аралашу чарасы буларак үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булалар.

Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә, шулай ук рус телле укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәрә.

**7 нче сыйныфны тәмамлаган рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр:**

- сөйләм этикеты үрнәкләрен урынлы куллануга ирешү;
- авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә дөрес әйтүгә ирешү һәм сингармонизм законының асылына төшенү;
- сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыра белү, тыңланган яки укылган текстның эчтәлеген сөйләп бирә алу;
- коммуникатив максатларны аңлап, диалогик аралашуда катнашу, тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле монологик сөйләм төзи алу;
- гади һәм кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү;
- тамыр, ясалма, кушма, парлы сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын белү;
- антонимнар, синонимнар, фразеологик һәм башка төр сүзлекләрдән файдалана белү;
- тиешле (1600 сүз) күләмдә татар сүзләрен яттан белү;

**Укучылар әзерлегенә таләпләр:**

Тыңлап аңлау

- Аралашуда катнашучыларның сөйләмен тыңлап аңлап, үз фикереңне аңлаешлы белдерү;
- өч минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлегенә караган биремнәрне телдән яки язмача эшләү.

Диалогик һәм монологик сөйләм.

- Төрле репликаларны кулланып, лексик темага сөйләшү үткәрү (һәр репликаның саны 9 дан ким булмаска тиеш);

- сөйләшү барышында үз фикереңне төгәл һәм эзлекле белдерү;
- тәкъдим ителгән темага монолог төзеп сөйләү (җөмләләр саны уннан ким булмаска тиеш).
- өстәмә чыганаклардан һәм вакытлы матбугаттан файдаланып, яңалыклар турында хәбәр итү;
- укылган яки тыңланган текстның эчәлеген кыскача яки тулы итеп сөйләү

Уку.

- Төрле жанрдагы текстларны эчтән уку һәм эчәлеген кыскача яки тулы итеп сөйләп бирү;
- текст белән танышып чыгып, эчтәлеге буенча төп мәгълүматны әйтеп бирү;- татар әдипләренең иҗаты турында белгәннәрне әйтеп бирү;
- шигырьләрне яттан сөйләү.

Язу.

- Лексик темаларга караган сүзләрне дөрес язу;
- укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген язмача сөйләп бирү;
- тәкъдим ителгән темага инша язу;
- аралашу гыйбарәләрен кулланып, хат язу.

| Дәрес № | Дәрес темасы | Лексика | Контрольгә алынырга тиешле белем һәм күнекмәләр | Число План | Число Факт |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Настоящие друзья”.<br><br>“Чын дуслар” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Аңа рәхәт булды, ашар, укучы өчен, почмак өчен, тын гына, дәшмәде, үзләреннән калган | Тема буенча лексиканы белү. Кем өчен, нәрсә өчен төзелмәсен җөмләләрдә куллана белү | 7.09 | |
| 2 | Определительные местоимения”.<br><br>Билгеләү алмашлыклары. | һәр | Билгеләү алмашлыкларын: һәркайсы, һәркем, һәрбер сөйләмдә куллана белү | 14.09 | |
| 3 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Новые сани”.<br><br>“Яңа чана” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Карагыз әле, биреп тор әле, рәхәт, саклап тот, шатланды, саран, ялкау, рәхәтләнеп, кулын селтәде, ватарсың, кызгана, үрти башладылар | Тема буенча лексиканы белү. Тулы, ким җөмләләр, хәл фигыль, килеш кушымчаларын куллана белү | 21.09 | |
| 4 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Друзья Саши”.<br><br>“Сашаның дуслары” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | әби өчен дару, зинһар, ярдәм итегез, кан басымы | Фигыльнең теләк белдерү формасы, җыю саны, туры сөйләм, күрсәтү алмашлыгын куллану | 28.09 | |
| 5 | Написание рассказа “Друзья Саши” с изменениями.<br><br>“Сашаның дуслары” хикәясен үзгәртеп язу. | әби өчен дару, зинһар, ярдәм итегез, кан басымы | Чын дуслыкка бәя бирү | 5.10 | |
| 6 | Лексико-грамматический материал в рассказе “В | сөт алырга кушты, эшчән, әдәпле, игътибарлы, яфрак яра, | Әзерлисе бар төзелмәсе; укыйсым бар төзелмәсе; | 12.10 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | походе в кино”.<br><br>“Кинога барганда” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | бал кортлары, аяклары җиргә тими | фразеологизмнарны куллану | | |
| 7 | Повторение по теме “Друг должен быть лучше тебя”.<br><br>“Иптәшең үзеңнән яхшы булсын” темасы буенча кабатлау. | -/- | Тема буенча лексиканы кабатлау | 19.10 | |
| 8 | Праздник дня рождения.<br><br>Туган көн бәйрәме. | -/- | Туган көнгә чакыру кәгазе яза белү | 26.10 | |
| 9 | Формы речи по теме угощения, приглашения в гости.<br><br>Кунак чакыру, сыйлау формалары. | кадерле, гафу ит, авыз ит, бер чынаяк чәй эч | Табынга чакыра, сыйлый белү | 9.11 | |
| 10 | Стихотворение Ш.Галиева “Гости”.<br><br>Ш.Галиевның “Кунаклар” шигыре. | өлеш, һәркемгә, татарча ризык исемнәре | Шигырьне яттан сөйләү | 16.11 | |
| 11 | Анекдоты о дне рождения.<br><br>Туган көн мәзәкләре. | мәзәк, мендек, буй, башваткыч, сикерә | Татар халык авыз иҗатын белү | 23.11 | |
| 12 | Повторение по теме “День рождение – весёлый праздник”. | -/- | Тема буенча лексиканы кабатлау | 30.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | “Туган көн – күңелле бәйрәм” темасы буенча кабатлау. | | | | |
| 13 | “День рождение – веселый праздник”.<br><br>“Туган көн – күңелле бәйрәм”. | | | 7.12 | |
| 14 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Юлдаш – деревенская собака”.<br><br>“Юлдаш – авыл эте” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | -/- | Җөмләдән ия белән хәбәрне таба белү | 14.12 | |
| 15 | Формы выражения глаголов: конструкция хочу писать.<br><br>Фигыльнең теләк белдерү формасы: язасым килә төзелмәсе. | -/- | Үз теләгеңне өйрәнелгән грамматик категория аша әйтә белү | 21.12 | |
| 16 | Присоединение падежных окончаний к существительным.<br><br>Исемгә килеш кушымчалары ялгану. | тәмлетамак, күсе, бәдрәф, иркәли, мәгънәсез, харап булган, хәйлә, кара-каршы, ялганлама, иртүк | Пьесасыны сәхнәләштерү; ничек барырга икән төзелмәсе | 11.01 | |
| 17 | Глагол условного наклонения. | -/- | Шарт фигыльне сөйләмдә куллана белү | 18.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Шарт фигыль. | | | | |
| 18 | Письмо бабушке.<br><br>Әбигә хат язу. | башлау, тәмамлау, хәл сорашу | Хат яза белү | 25.01 | |
| 19 | Формы времен глагола изъявительного наклонения неопределенного прошедшего времени.<br><br>Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең заман формалары. | юк иткәннәр, хәбәр, кичкән, яралы, сугыш кыры, элемтәче | Бөек ватан сугышында этләрнең батырлыгы турында сөйләшү | 1.02 | |
| 20 | Повторение грамматики по теме “Четвероногие друзья”.<br><br>“Дүрт аяклы дусларыбыз” темасы буенча грамматиканы кабатлау. | -/- | Тема буенча лексиканы кабатлау | 8.02 | |
| 21 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Дедушка Радика”.<br><br>“Радикның бабасы” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | хис итә, чыныгу, зарарлы, гадәтләр, төгәл үти, тәмәке тарта, чирәм | Текстның эчтәлеген сөйләү | 15.02 | |
| 22 | Конструкция инфинитив+нужно.<br><br>Инфинитив + кирәк төзелмәсе. | куркыныч | Сәламәт яшәү өчен киңәш бирә белү | 22.02 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 23 | Лексико-грамматический материал в биографии Гаты Камского.<br><br>Гата Камскийның биографик белешмәсендәге лексик-грамматик материал. | ачыш, ясый, ихтыяр,көче, таж, якташ, горурланабыз | Инфинитив + өйрәтте төзелмәсе | 1.03 | |
| 24 | Конструкция Инфинитив +можно, надо, должен.<br><br>Инфинитив+ярый, кирәк, тиеш төзелмәсе. | ашыгырга, юл аркылы | Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү | 8.03 | |
| 25 | Глагол условного наклонения.<br><br>Шарт фигыль. | сыбызгы, сызгырта | Хикәяне сәхнәләштерү | 15.03 | |
| 26 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Собака Олега Бим”.<br><br>“Олегның эте Бим” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | иснәде, бау, тарта, узып бара | Лексиканы кабатлау | 22.03 | |
| 27 | Определенное прошедшее время глагола изъявительного наклонения.<br><br>Билгеле үткән заман хикәя фигыль. | белем көне, дәреслек, ял итү, тырыштым, булыштым, аеруча, искиткеч | Билгеле үткән заман хикәя фигыльне кабатлау | 5.04 | |
| 28 | Деепричастие. | -/- | Хәл фигыльне белү | 12.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Хәл фигыль. | | | | |
| 29 | Главные члены предложения.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. | Тема буенча лексика | Җөмләнең баш кисәкләрен истә калдыру | 19.04 | |
| 30 | Союз из-за.<br><br>Күрә бәйлеге. | көндәлек, дәреслек, өй эше, хата, билге, акыллы | Күрә бәйлеген сөйләмдә куллану | 26.04 | |
| 31 | Сүзләргә кушымчалар ялгану тәртибе | китапханә, теләк, тәрбияле, җитди | Сүзләргә кушымчалар ялгану тәртибен белү | 3.05 | |
| 32 | Лексико-грамматический материал в стихотворении З.Туфайлова “Самат”.<br><br>З.Туфайлова “Самат” шигырендәге лексик-грамматик материал. | ыргыткан, ертылган, саклап тотмаган | Боерык фигыль | 10.05 | |
| 33 | Лексико-грамматический материал в произведении Ш.Маннура “Совет”.<br><br>Ш.Маннур “Киңәш” әсәрендәге лексик-грамматик материал. | ялгыш, киңәш, дөрес, җитдм, яңалык, белемле, максатка ирешүчән | Боерык фигыль | 17.05 | |
| 34 | Определенное будущее время глагола изъявительного наклонения.<br><br>Билгеле киләчәк заман хикәя фигыль. | -/- | Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльне белү | 24.05 | |
| 35 | Лексико-грамматический материал в рассказе М | әдәбият, әдип, әсәр, җөмлә, буталды, басым, дәлиллә | Хәл фигыль формаларын белү | 31.05 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Махдиева “На уроке русского языка”. М.Мәһдиевнең “Рус теле дәресендә” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | | | | |

**Рус телендә сөйләшүче балаларның сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча туган (татар) теленнән белем һәм күнекмәләрен бәяләү.**

Күнекмәләрне бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

**Тыңланган текстның эчтәлеге буенча соауларга җавап бирүне бәяләү**

Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап,тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән,1 орфографик хатасы яки эчтәлеккә бәйле 1 хатасы булган эшкә “5”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеген аңлап,тәкъдим ителгән сорауларга дөрес җавап бирелгән,әмма 2-3 орфографик ,3 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 2-3 хатасы булган эшкә “4”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеген өлешчә аңлап,тәкъдим ителгән сорауларга төгәл җавап бирелмәгән,5 орфографик,5 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 4-5 хатасы булган эшкә “3”ле куела. Тыңланган текстның эчтәлеге буенча тәкъдим ителгән сорауларга бирелгән җавапларның яртысы дөрес булмаса,6 орфографик,6 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 5 тән артык хатасы булган эшкә”2”ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда,әйтелеше,грамматик төзелеше ягыннан дөрес,эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә,”5”ле куела. Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә,”4”ле куела. Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда,репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп,эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә,”3”ле куела. Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда “2”ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше,грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы,эзлекле монологик сөйләм өчен “5”ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән,әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә,грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хаталы монологик сөйләм өчен “4” ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән,сүзләрнең әйтелешендә,җөмлә төзелешендә 4-7 хаталы онологик сөйләм өчен “3”ле куела. Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча монолог төзи алмаганда,”2”ле куела.

**Укуны бәяләү**

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап,сәнгатьле һәм аңалешлы итеп укыганда,”5”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап,сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда,әмма 2-3 орфоэпик хата булганда,”4”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда,4-6 тупас орфоэпик хата булганда,”3”ле куела. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча,орфоэпик кагыйдәләрне бозып укыганда,”2”ле куела.

**Сүзлек диктанты һәм аны бәяләү** Пөхтә,төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә “5”ле куела. Пөхтә,төгәл язылган,1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булган эшкә “4” ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган,4-5 төзәтүе яки 3-5 орфографик хатасы булган эшкә”3” ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган,6 яки артыграк орографик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

## Эш программасына төзәтмәләр кертү бите

| Класс | Дәрес темасы | План буенча үткәрү вакыты | Төзәтмәләр кертүнең сәбәбе | Төзәтмәләр кертү чаралары | Фактта үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |